ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 27 марты** **Чистай шәһәре** **№ 156**

“Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының
2015 елның 30 октябрендәге “Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү
өчен сатып алулар планын булдыру, раслау һәм алып
бару тәртибен раслау турында”гы 640 номерлы карарын
үз көчен югалткан дип тану хакында”.

2015 елның 30 октябрендәге “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында”гы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 640 номерлы карарына Чистай шәһәре прокуратурасының 2020 елның 23 мартындагы 02-08-02-2020 номерлы протестын карап чыкканнан соң, 2019 елның 1 маендагы “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында”гы 71 номерлы Федераль закон белән танылуга бәйле рәвештә, 2013 елның 5 апрелендәге “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында”гы 44 номерлы Федераль законның 17 статьялары үз көчләрен югалткан дип тану һәм 2019 елның 30 сентябрендәге “Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау, мондый планнарга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында закупкаларның план-графикларын урнаштыру тәртибен билгеләү, мәгълүматны закупкалар планнары-графиклары рәвешенә карата һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында мәгълүматны кертү үзенчәлекләрен билгеләү хакында”гы 1279 номерлы РФ Хөкүмәте карары, 2013 елның 21 ноябрендәге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең үз көчен югалткан “Россия Федерациясе субъекты ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу планнарын, шулай ук товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу планнарын формалаштыруга, раслауга һәм алып баруга таләпләр турында”гы 1043 номерлы карарының, һәм 2013 елның 5 апрелендәге “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында”гы 44 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 30 октябрендәге “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында” 640 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Л.Х. Кашаповка йөкләргә.

Башкарма комитеты
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов